| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.10.2025 г.Лениногорск № 873

Лениногорск муниципаль районы территориясендә даими рәвештә җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның гаиләләренә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр яны җир транспортында балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлыФедераль законына таянып, Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Лениногорск муниципаль районы территориясендә даими рәвештә җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе» ДБББУдә белем алучы сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның гаиләләренә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр яны җир транспортында балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә өстәмә социаль ярдәм күрсәтүнең тәртибен расларга.

2.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru)урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы З.Г.Михайлова

М.Г. Якупов
5-15-41